ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2022 елның 8 декабреннән N 18

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районының
Бәзәкә авыл җирлегендә бюджет
процессы турында нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Советының 2022 елның 22 мартындагы 2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәнең 15 статьясындагы 2 пунктының 1 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1) Евразия икътисадый берлеге хокукы һәм таможня җайга салуы турында Россия Федерациясе законнары белән каралган бюджет дефицитын финанслау чыганаклары буенча керемнәрне һәм түләүләрне (бюджетның бердәм счетындагы калган акчалар белән идарә итү операцияләреннән, бердәм салым түләүләренә бәйле операцияләрдән, Евразия икътисадый берлеге хокукы һәм Россия Федерациясе законнары белән мәҗбүри түләүләргә карата каралган аванс түләүләренә бәйле операцияләрдән, каралган акчалата залогка бәйле операцияләрдән тыш) планлаштыруны (фаразлауны) гамәлгә ашыра.

2. Әлеге карарны Бәзәкә авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында "Бәзәкә авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе И.И.Кәшәфетдинов